ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БЕТЬКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422649, с. Бетьки,
ул. Мира, дом 11

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘТКЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422649, Бәтке авылы,
Мир урамы, 11 нче йорт

Тел.: (84361) 26235, факс: (84361) 26235, e-mail:bet.rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

Бәтке ав. №5 08.07.2020ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибен раслау турында

“Татарстан Республикасындагражданнармөрәҗәгатьләретурында” 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы таләпләренигезендә

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсемуниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә кушымта итеп бирелә торган анализ үткәрүТәртибен расларга (кушымта ).

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитеты сәркатибенә ярты елның соңгы аеннан соң килүче айның 10 числосыннан да соңга калмыйча елга ике мәртәбә гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясауны гамәлгә ашырырга.

3. Анализ үткәрү нәтиҗәләрен ярты еллыкның соңгы аеннан соң килүче айның 15 числосыннан да соңга калмыйча Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адрес буенча рәсми сайтында урнаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Бәтке авылы,Ленин урамы,4 йорт; Яншык авылы, Җиңүнең 40 еллыгы урамы, 23 йорт; Кече Укмас авылы, Гагарин урамы, 9Б йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында (стендларында)һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсемуниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге Башлыгы Ф.М.Динмөхәммәтов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге
Башкарма комитеты боерыгы
белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсемуниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан РеспубликасыЗаконының 23 маддәсен үтәү йөзеннән эшләнде һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсемуниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнарның кергән мөрәҗәгатьләрен гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын тәгаенли.

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитетына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау, гражданнарның җәмәгатьчелек фикерен һәм актуаль проблемаларын өйрәнү, шулай ук гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү рәвешләрен һәм ысулларын камилләштерү, аларның хокукларын һәм кануни мәнфәгатьләрен яклауның сыйфатын күтәрү максатларында уздырыла.

3.Тиешле чорда гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ барлык мөрәҗәгатьләр буенча, шул исәптән язма рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган Интернет-кабул итү бүлмәсе аша электрон документ рәвешендә, шулай ук гражданнарны вәкаләтле затлар тарафыннан шәхсән кабул итү барышында кабул ителгән мөрәҗәгатьләр буенча гамәлгә ашырыла.

4.Анализда кергән, башка адрес буенча юлланган һәм каралган язма мөрәҗәгатьләрнең, электрон документ рәвешендәге мөрәҗәгатьләрнең саны, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре, шәхсән кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны, гражданнарны шәхсән кабул итү һәм читкә чыгып кабул иткән вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы турында, мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар, шул исәптән кабул ителгән норматив-хокукый һәм башка актлар (булса) турында мәгълүмат булырга тиеш.

5.Мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитетының тиешле вәкаләтләр бирелгән урындагы заты (алга таба - вәкаләтле зат) тарафыннан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитетының җаваплы хезмәткәрләре тарафыннан бирелгән гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча мәгълүматлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

6.Мөрәҗәгатьләр белән эшләү торышы (гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ) мәҗбүри тәртиптә Татарстан Республикасы Балык

Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында кушымта итеп бирелә торган рәвештә урнаштырыла (1 нче кушымта).

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү Тәртибенә кушымта №1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү турында

СТАТИСТИК МӘГЪЛҮМАТЛАР

| № п/п | Мәгълүматларның аталышы | Саны (данә) |
|---|---|---|
| **1.** | **Кергән мөрәҗәгатьләр БАРЛЫГЫ:** | |
| 1.1 | шулардан | |
| 1.1.2 | язма рәвештә | |
| 1.1.2.1 | электрон рәвештә керде | |
| 1.1.3 | телдән | |
| **2.** | **Тематика:** | |
| 2.1 | торак мәсьәләсе | |
| 2.1.1. | 2.1 биттән<br>шул исәптән:исәпкә кую, торак шартларын яхшырту мәсьәләләре | |
| 2.1.2 | торак булмаганнан торакка, торак булганнан торак булмаганга күчерү | |
| 2.1.3 | бүлмәләрнеяңаданпланлашты ру/үзгәртеп кору | |
| 2.2 | Төзекләндерү (уңайлылык булдыру) мәсьәләләре | |
| 2.2.1 | 2.2 юлдан | |
| | төзелешматериалларынюю (урнаштыруга) рөхсәтнамә | |
| 2.2.2 | агачларны кисү | |
| 2.2.3 | төзекләндерүнең бүтән мәсьәләләре | |
| 2.2.6 | урамнарны яктырту | |
| 2.3 | адрес бирү | |
| 2.3.1 | 2.3 биттән<br>шулисәптән:адрес бирү административ регламент беләнҗайгасалынаторганобъе ктларга | |
| 2.4 | тору урыны буенча теркәү | |
| 2.5 | җир мәсьәләләре (чикләрне килештерү) | |
| 2.6 | белешмәләр бирү | |
| 2.6.1 | 2.6 биттән | |

| | | |
|---|---|---|
| | шул исәптән, бирү административ регламент белән җайга салына торган белешмәләр | |
| 2.7. | башка бүтәннәр | |
| **3.**<br>3.1 | **1 биттән:**<br>канәгатьләндерелде | |
| 3.2 | кире кагылды | |
| 3.3 | аңлатма бирелде | |
| 3.4 | башка оешмаларга юлланды: | |
| 3.5 | кире кайтарылды: | |
| 3.6 | эштә: | |